**ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**«25» март 2026 ел № 1**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең Наласа авылында халык җыенынәтиҗәләре турында» 2025 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең Наласа авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Наласа авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлегенең Наласа авылында 2026 елның 25 мартында "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлегенең Наласа авылында халык җыены нәтиҗәләре турында" 2025 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча узган халык җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авылы, Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Наласа авылында М. Вахитов һәм Яшьләр урамнары буенча су агызу торбаларын алыштыруга материаллар сатып алу, һәм урнаштыру);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу һәм урнаштыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Наласа авылында тимер-бетон боҗралар сатып алу (3 данә),эчке краннарын алыштыру).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 489 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 255 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 255 кеше тавыш бирде;
" Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә Наласа авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Халык җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү мәсьәләсе буенча карарны танырга: «Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авылы, Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Наласа авылында М. Вахитов һәм Яшьләр урамнары буенча су агызу торбаларын алыштыруга материаллар сатып алу, һәм урнаштыру);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу һәм урнаштыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Наласа авылында тимер-бетон боҗралар сатып алу (3 данә),эчке краннарын алыштыру).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда кабул ителгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә, карар кабул ителгән дип танырга».

255- "ӘЙЕ" 0- "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт

адресы  буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча  һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы  буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен  җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге башлыгы Шакирова И.Р